ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

17 июля 2026 ел

№ 7119

«Шәһәр транспорты» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Шәһәр транспорты» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Башкарма комитетның «Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2025 елның 7 мартындагы 1705 номерлы Карары;

2) Башкарма комитетның «Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2025 елның 9 июнендәге 4116 номерлы Карары;

3) Башкарма комитетның «Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2025 елның 9 июнендәге 4117 номерлы Карары;

4) Башкарма комитетның «НЕФАЗ-5299 автобусы белән оешмаларның пассажирларын йөртү (вахта) буенча «Горкоммунхоз» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәткә тарифны раслау турында» 2025 елның 9 октябрендәге 8162 номерлы Карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 17 июлендәге
7119 номерлы карарына
кушымта

«Шәһәр транспорты» МУП тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Бәясе, сум | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|
| 1. | Техник шартлар бирү | 12 660,72 | 1 хезмәт |
| 2. | Экскурсия үткәрү өчен йөртүче белән трамвай вагоны бирү | 4 509,50 | 1 сәгать |
| 3. | 7 нче ярдәмче станциясендә (ТП–7) РУ-10 кВ да КРУ-2 ячейкасының электр җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | 3 339,88 | 1 хезмәт |
| 4. | НЕФАЗ-5299 автобусы белән оешмаларның пассажирларын йөртү (вахта), ягулык-майлау материалларын исәпкә алып | 6 295,46 | 1 сәгать |
| 5. | SOLLERS Atlant автобусы белән оешмаларның пассажирларын йөртү (вахта), ягулык-майлау материалларын исәпкә алып | 2 636,59 | 1 сәгать |
| 6. | Автотранспортны ремонтлау | 3 050, 00 | 1 сәгать |
| 7. | Белгечнең ГАЗ-А31R32 автомобилендә ремонт урынына баруы | 5 512,25 | 1 сәгать |
| 8. | Эвакуациягә әзерлек (шул исәптән карданны, ярымкүчәрне салдыру) | 13 166,18 | 1 хезмәт |
| 9. | Эвакуатор хезмәтләре йөксез (буш) (Камаз 541000) | 128,25 | 1 км |
| 10. | Эвакуатор хезмәтләре йөк белән (буксирлау) (Камаз 541000) | 316,31 | 1 км |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Н.И. Галиева